**Урта мәктәптә мәзәк жанрын өйрәтү тәҗрибәсеннән**

Л.Ф.Җамалиева, филол.фәнн. канд., доцент
ИФИ КФУ, Ф.Закирова 5 курс студенты

Татар халкының мең елларга сузылган тормышында тупланган тәҗрибәсе, гадәтләре, кешене шәхес итүче сыйфатлары, бай тарихы бар. Шуларга мөрәҗәгать итү тәрбия эшенең нәтиҗәлелеген көчәйтә. Ә тәрбия, беренче чиратта, мәктәптә бирелә. Без укучыларны әдәбият дәресләрендә әдәби әсәрләр аша тәрбияләргә омтылабыз. Халык авыз иҗаты әсәрләре бу очракта менә дигән үрнәк булып торалар. “Хәтердән башка йолалар, тәрбиядән башка рухи хәзинә, рухи хәзинәдән башка шәхес, ә шәхестән башка халык – тарихсыз”, – дип әйтелә халыкта.

Әдәбият дәреслекләрендә халак авыз иҗаты әсәрләре уңышлы гына бүленеш тапкан. Безнең исә, фольклорда аерым бер урын тоткан мәзәк жанрына тукталасыбыз килде.

Татар мәктәпләрендә программа нигезендә мәзәк жанры белән танышу 5 нче сыйныфның әдәбият дәреслегендә каралган. Мәзәккә билгеләмә биреп кителә һәм аңлатмалары белән берничә мисал күрсәтелә. Аннан кала “Ишәк өстендә”, “Шайтан ни төсле”, “Аягын күтәрә торган ат”, “Укытучы белән укучы бала”, “Тартылмый да, сузылмый да”, “Өметсез”, “Төбендә юкмы”, “Былтыргы “А” дип исемләнгән мәзәкләр китерелә. Әйтергә кирәк, әлеге мәзәкләр шулкадәр кызыклы һәм отышлы сайланган дип әйтеп булмый. Ни дисәң дә, 5 нче класс баласына бераз гадирәк, үз тормышына якынрак, үз иптәшләре арасында булырдай мәзәкләр бирү кирәктер. Дәреслектә бирелгән әлеге берничә мәзәк белән генә баланың күңеленә үтеп керергә мөмкин түгел. Без бит шушы мәзәкләр белән беррәттән тәрбия бирү процессын да бәйләп алып барырга тиеш. Материалның сыйфаты никадәр начар булган саен тәрбия бирү дәрәҗәсе дә шулкадәр нәтиҗәсезрәк була.

Бала күңеленә хуш килердәй әлеге мәзәкләрне каян табарга мөмкин соң? Әллә инде хәзер балаларыбыз да газета-журнал битләреннән, радио-телевидениедән “очсызлы”, оятсыз мәзәкләр укып-карап утырырга тиешме? Юк! Моңа юл куярга ярамый. Игътибар белән күңел сандыгыбызны, әдәби-

мәдәни мирасыбызны барласак, без Хуҗа Насретдин мәзәкләре циклына тап булабыз. Ә Хуҗа Насретдин мәзәкләре инде нәкъ тә менә без эзләгән материал ул. Хуҗа Насретдин диюгә, һәрберебезнең иренenә елмаю йөгерә. Хуҗаны белмәгән, ишетмәгән кеше юктыр, мөгаен. Аның исеме дуслык мәҗлесләрендә дә, сәяси чыгышларда да, фәнни бәхәсләрдә дә телгә алына. Чөнки ул һәртөрле ситуациядә калган халык герое: алдаган һәм алданган, хәйлә белән котылган, кайчакта бик акыллы, кайчакта чын юләр булып күренгән. Әйтерсең, менә инде ул мең елга якын кешелекнең наданлыгыннан көлә. Әйтеп үтәргә кирәк, Хуҗа Насретдин мәзәкләренең тәрбияви әһәмияте башка мәзәкләргә караганда югарырак баскычта тора. Аларда бернинди оятсызлык, эчкерлелек юк.

Өстәп шуны да әйтергә кирәк, 5 нче сыйныфның әдәбият дәреслегендә Нәкый Исәнбәтнең Хуҗа Насретдин мәзәкләренә нигезләнеп язылган “Хуҗа Насретдин” комедиясе дә бирелә. Билгеле, әлеге комедия мәзәкләрдән бераз соңрак өйрәнелә. Әмма комедияне өйрәнгәндә дә Хуҗа Насретдин мәзәкләренә мөрәҗәгать итү уңышлы булыр иде. Укучыларга Нәкый Исәнбәтнең олуг фольклорчы, мәзәкләрне җыю һәм фәнни өйрәнү өлкәсендә дә дә шактый эшләр башкарган галим икәнлеген искәртеп үтми мөмкин түгел.

Хуҗа Насретдин мәзәкләрен сыйныф сәгатьләрендә, класстан тыш чараларда файдаланырга мөмкин. Класстан тыш чараның темасына карап мәзәкләрне сайлап алырга була. Чөнки Хуҗа Насретдин мәзәкләре арасында һәртөрле темага карганнары да бар.

Мәзәкләр – халкыбызның рухи-әхлакый идеалларын чагылдыручы төп категорияләрнең берсе. Татар фольклорына караган башка жанрлар кебек үк, мәзәкләр дә иң беренче чиратта тәрбияви үзенчәлеккә ия булуын күрәбез. Мәзәкләрнең һәрберсеннән зирәк фикер аерып алырга мөмкин. Аның төп идея-эстетик кыйммәте тормыштагы төрле тискәре күренешләрне сатира-юмор ярдәмендә фаш кылуы, әдәп-әхлак нормаларын ныгытуга, кешеләрдә, бигрәк тә яшь буында югары рухи сыйфатлар тәрбияләүгә ярдәм итүе белән

билгеләнә. Үзенең тапкырлыгы һәм көтелмәгәнчә тәмамлануы белән мәзәк тыңлаучының хисләрен кузгата, гаҗәеп акыл зирәклеге белән шаккаттыра. Мәзәк тормышның бөтен якларын иңли. Кешеләрдәге кимчелекләрне, мөнәсәбәтләрдәге тупаслыкны ул оста тотып ала.

Мәзәкләрдә тискәре герой гадәттә үзенең бер сыйфаты буенча гына сурәтләнә (йә ул бак ялкау, йә бик саран, йә бик ялганчы, йә бик надан, йә бик мактанчык һ.б.). Әйтик, ялкау хәтта ашарга да иренә; ялганчы үз гомеренә бер дөрес сүз дә әйтми; комсыз, күршесенең морҗасыннан төтен чыкканны күргәч, кереп аның ашын ашап чыгарга ымсына башлый.

Мәзәкләрдә геройларны бер-берсенә каршы кую алымы (патша – крестьян; бай – ярлы; тырыш – ялкау; белемле – надан; юмарт – саран һ.б.) шактый еш кулланыла.

Мәзәк герое берничә ситуациянең нәтиҗәсен йә аңлы рәвештә (формаль яктан аның моңа хакы бар, чөнки ситуацияләр охшаш), йә ахмаклыгы аркасында икенче очракта да файдалана. Шуның белән ул үзенең дошманын мәсхәрәгә төшерә (яки үзе көлкегә кала).

Мәзәк текстларында бетем өлешенең үткенлеген, җорлыгын, тапкырлыгын көчәйтү максатында такмак-такмазалар, мәкаль-әйтемнәр, янәшәлекләр, чагыштырулар, ирония, гипербола кебек тел-стиль һәм сурәт чаралары киң файдаланыла. Димәк, мәзәкләрне мәктәптә татар теле дәресләрендә кулланырга мөкин дигән сүз бу.

Мәзәк гомер-гомергә халыкның аерылгысыз юлдашы, киңәшчесе, акыл, үгет-нәсихәт бирүчесе булып килгән. Шуңа күрә мәзәкләрне өйрәткәндә әлеге жанрга игътибарны арттыру зыян итмәс.